ТР “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге
“Зәй-Каратай төп гомуми белем бирү мәктәбе”
муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе

Кабул ителде

Педагогик киңәшмәдә

Беркетмә № _____________2018 нче ел

гамәлгә кертелде

______ нче боерык нигезендә

мәктәп директоры _________ Әхмәтова Л.Ш.

“Туган якны өйрәнү” түгәрәгенең

**ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

(Атнага 1 сәгатьтән, елга 35 сәгать)

Төзүче: Галиуллина Асия Хәйдәр кызы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты,

рус теле һәм әдәбияты укытучысы

КАРАЛДЫ
МБ утырышында ____________ 2018 нче ел. Беркетмә №
Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары _________

2018 нче ел

Аңлатма язуы

*Ватан –кешеләрнең хөрмәте һәм һәркем хозурында тора торган кадерле бер мактанычыдыр... Шуның өчен малыгызны кызганмагыз, көчләрегезне аямагыз, Ватан хакына болай фидакяр булмаган кеше анда яшәргә лаек түгелдер.*
Риза Фәхретдин

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз.Ә ул үз чиратында , туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш.Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала.

Тәрбия эшендә Ватан темасы үлемсез. Ватан - кешенең изге туган җире. ”Ватан - кеше үзе туган һәм шуның гражданины булган ил; туган ил; кешенең туган ягы, туган җире” дип аңлатма бирелә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә. Ә Ватанын сөючене без патриот дибез. Патриот - Ватанын , туган җирен, халкын, илен сөюче генә түгел, ә шулар өчен һәртөрле корбаннарга әзер булган кеше.Кеше яшьтән үк яхшы белән начарны, түбәнлек белән бөеклекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш. Патриотик тәрбия дигәндә, без балаларны милли үзаңга һәм гражданлык эшенә ия булган шәхесләр, Ватанның лаеклы уллары, кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Патриотлык - Ватанга мәхәббәт хисе, аның тарихы, мәдәнияте , казанышлары белән кызыксыну, милли символларга, изге урыннарга хөрмәт белән карау, җәмгыятькә һәм халкыңа хезмәт итәргә әзер булу.

Туган якны яратырга өйрәтү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү- <u>патриотик тәрбия бирү</u>нең беренче адымы. Патриотизм орлыклары гаиләдә үк салынырга тиеш. Кешенең нинди мохиттә тәрбияләнүе тормышта зур роль уйный. Укучыларны җанга рухи дәва бирүче туган як табигате, аның сихри көчкә ия булган чишмәләре, сабый чакта уйнап үскән хәтфә үләнле болыннары аша туган илебезне чын күңеленнән яратучы, милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр - Ватанның лаеклы уллары һәм кызлары итеп тәрбияләү патриотизм тәрбияләү өчен мөһим шарт булып тора. Бишек җырларыннан, ана теленнән башлап, балаларыбыз әйләнә-тирәбездәге бар нәрсәне яратырга тиеш - әти-әнисен, дусларын, үзе уйнап үскән яшел чирәмле урамын, өен, кичке шәфәкъ балкышын, туган якларын калдырып киткән торна тавышларын, яңа чабылган үлән исен ...Чын йөрәге белән тоеп ярата

белгән кеше генә туган иленең патриоты була ала.Үзенең кече Ватаны табигатенә рухы белән бәйләнгән кеше генә һәр агач, чәчәк, җәнлек, бөҗәк һәм һәр кеше язмышы өчен үзендә җаваплылык тояр.

Патриотик тәрбия бирүнең икенче адымы-<u>туган як тарихын өйрәнү.</u>Туган як тарихы ул - шунда яшәгән кешеләр тарихы.Кешенең тарихта тамырлары гаиләсенең традицияләрендә, халкының, туган ягының үткәнендә. Туган як тарихын өйрәнү укучыларга үз төбәкләрендә яшәгән кешеләр турында күбрәк белергә, якыннан танышырга мөмкинлек бирә.Аларның тормыш-яшәешләре укучыларда соклану һәм горурлану хисләре уята, өлкән буын кешеләренә карата хөрмәт тәрбияли.Без үсеп килүче буынга үзенең әтисе, гаиләсе, бабалары эшләрен дәвам итүче икәнен, аның тормышы, нәселе дәүләтнең һәм, ниһаять, илнең бер кисәге икәнен аңлатырга тиешбез .

Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк.Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең тарихын белергә, шуның аркылы халык тарихына якынаерга тиеш. Шәҗәрәләр төзү нәсел-ыру традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен кирәк. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала.

Патриотик тәрбия бирүдә тагын мөһим чараларның берсе -музейлардагы хәзинәне - тарихи экспонатларны, халкыбызның рухи һәм матди культурасын , бүгенгесен һәм узганын чагылдыручы кыймматле материалларны куллану.Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Музейлар шулай ук туган якның , туган авылның , туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәм итә.

Патриотик тәрбия бирүне халкыбыз узган сугышчан юл белән таныштыру аша алып бару гаять тә отышлы. Туган илне ихтирам итү, патриотизм хисләрен туган җиреннән аерылып , Ватан өчен утка кергән авылдашлар язмышы, аларның кичерешләре аша тәрбияләүдән дә отышлырак чара бармы соң? Сугыш һәм тыл ветраннары белән очрашулар , ялгыз яшәүче әби-бабайларга ярдәм күрсәтү- һәрберсе дә укучылар күңелендә өлкән буынга хөрмәт тәрбияли. Музейга кергән һәр бала ветераннарга багышланган стенд, альбом, экспонатларны күрә,бигрәк тә кече яшьтәгеләр ныграк кызыксына, күп сораулар яудыралар. Алар моннан илебез азатлыгы өчен көрәшкән кешеләрнең исемнәре алдагы буыннарга җитәчәген аңлап чыга.

Музейда үткәрелгән очрашулар, экскурсия, дәресләр , туган якка кагылышлы җирле материалларны өйрәтү аша балалар күңеленә патриотизм орлыклары салына. Мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр - укучыларга чын-чынлап илһам чыганагы.Балаларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү,тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек максатларга ирешү өчен музей материаллары - чиксез бай хәзинә.

Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота.Укучы үзе яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен аеруча яхшы белергә тиеш.

Тарихны сөйләп кенә бала күңеленә сеңдереп булмый.Бала эшчәнлеккә үзе катнашканда гына , үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тотып караганда гына үзе өчен ачышлар ясый һәм белмәгәннәрен бүтәннәргә җиткерә ала.

**“Туган якны өйрәнү” түгәрәге <u>түбәндәге максаттан</u> чыгып оештырыла**:

-үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү;

-укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага салу күнекмәләре формалаш-тыру;

-туган як белән кызыксынуларын үстерү һәм мәхәббәт тәрбияләү;

- туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Максатка ирешү өчен <u>түбәндәге бурычларны</u> хәл итү күздә тотыла:**

-укучыларга үзләренең нәсел тамырларына, үз гаиләләренең үткәненә кызыксыну уяту;

-туган як тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле шәхесләрне, мәгариф һәм сәнгать тарихын эзлекле өйрәнү;

-укучыларда милли үзаң формалаштыру;

-тарихи шәһәрләргә, табигатькә экскурсияләр үткәрү;

Өстәмә белем бирү буенча бу программа 6,7 нче класс укучылары өчен атнага

1 тапкыр 35 сәгатькә, бер уку елына төзелгән.

Программаның тематик бүленеше

| № п/п | Эш төре | Сәгать саны | | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Теория | Практика | План | факт | |
| 1. | Музейны тәртипкә китерү. | | 1 | 5.09 | | |
| 2. | Музей әгъзаларын музейның эш планы, алда торган бурычлар белән таныштыру. | 1 | | 12.09 | | |
| 3. | Авылым тарихы. Авылымның исеме каян килеп чыккан? | 1 | 1 | 19.09 | | |
| 4. | Өлкәннәр көненә чаралар: лаеклы ялда булган мәктәп һәм балалар бакчасы хезмәткәрләрен өйләренә барып котлау; укытучыларга котлау открыткалары язу | 1 | 1 | 26.09 | | |
| 5-6. | Колхоз тарихы | 2 | | 3.10<br>10.10 | | |
| 7 | Мәктәп тарихы *(Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу)* | 1 | | 17.10 | | |
| 8-9. | Авылыбыздан чыккан күренекле шәхесләрне барлауны, аларның тормыш юлын өйрәнүне дәвам итү. | 2 | | 24.10<br>7.11 | | |
| 10-11 | Алар безнең мәктәптә укыдылар *( Материаллар туплау)* | 2 | | 14.11<br>21.11 | | |
| 12-13 | Чишмәләрне барлау; аларның исемнәрен, ни өчен бу исем бирелгәнен ачыклау. | 2 | | 28.11<br>5.12 | | |
| 14-15. | “Элек шәмгә мохтаҗ яклар...”- Зәй-Каратай тарихында нефть табылу | 2 | | 19.12<br>9.01 | | |
| 16-17. | “Хезмәте барның – хөрмәте бар” - Нефтьче-авылдашлар турында материал туплау | 2 | | 16.01<br>23.01 | | |
| 18. | Интернационалист егетләребез турында мәгълүматны баету | | 1 | 30.01 | | |
| | Хәрби хезмәттә булган | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 19. | авылдашларга бәйрәм сәламнәре белән хатлар язу | 1 | | 6.02 | | |
| 20-21. | Мәктәптә хәрби-патриотик айлык. “Ватанны саклау- изге бурыч” Армия сафларыннан кайткан егетләр белән очрашу уздыру | 2 | | 13.02<br>20.02 | | |
| 22-23. | Кемнәр алар интернационалистлар? Алар Ватан алдындагы бурычларын үтәделәр | 2 | | 27.02<br>6.03 | | |
| 24. | “Акланган исем...”  Кемнәр алар Туйкиннар? | 1 | | 13.03 | | |
| 25-26. | “Тарихларда җуелмас сукмагы бар” Ф.Туйкин һәм К.Туйкиннарның иҗади эшчәнлеге | 2 | | 20.03<br>3.04 | | |
| 27 | “Бөек Җиңүгә 74 ел”. Музейда Бөек Ватан сугышы темасына багышланган экспозицияне яңарту. | 1 | | 10.04 | | |
| 28. | Бөек Җиңүнең 74 еллыгына багышланган “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” Викторина | 1 | | 17.04 | | |
| 29-30. | Митингка әзерләнү:<br>венок ясау;<br>чәчәкләр ясау | 2 | | 24.04<br>1.05 | | |
| 31. | “Хәтер китабы” буйлап сәяхәт. (“Хәтер китабы”ннан авылдашларның исемнәрен барлау) | | | 8.05 | | |
| 32 | “Музейда Бөек Ватан сугышы хатирәләре”.Интерактив экскурсия. | 1 | | 15.05 | | |
| 33-34 | “Һәйкәл куяр идем мин коеп” – тыл хезмәтчәәнәренең Бөек җиңүгә керткән өлеше | 2 | | 22.05<br>29.05 | | |
| 35 | Музей советының соңгы утырышы. Музей эшчәнлегенә нәтиҗә ясау. | 1 | | 30.05 | | |

**«Туган якны өйрәнү» түгәрәге әгъзаларының исемлеге**

1. Гимадиева Алинә
2. Идиатуллина Лиана
3. Мухаметова Зарина
4. Ширманов Илнур
5. Усманова Зульфия Ильдаровна
6. Мифтахова Жасмин

**Музейдагы 7 бүлекнең җаваплы кешеләре,**

**ягъни экскурсоводлар**

| № | Бүлекнең исеме | Җаваплы кеше | Класс |
|---|---|---|---|
| 1 | Туган авылым.<br>"Җир йөзендә шундый авыл бар –<br>Зәй-Каратай диләр исемен.<br>Уңган халкы, инеш-чишмәләре<br>Тәшкил итә аның җисемен" | Гимадиева Алинә | 5 |
| 2. | "Үткәннәрне өйрәнми торып, хәзергене белеп булмый" | Идиатуллина Лиана | 5 |
| 3. | "Башы гыйлем чишмәсенең, Мәктәп, бары синнән башлана" | Мифтахова Жасмин | 5 |
| 4.<br><br>5. | "Беркем дә бернәрсә дә онытылмас"<br>Авылдашларыбыз – интернационалистлар | Мухаметова Зарина | 5 |
| 6. | "Тарих бөтен фәннәрнең анасы, туган җирен яраткан һәр кеше үз тарихын белергә тиеш" (Туйкиннарга багышланган бүлек) | Усманова Зөлфия | 5 |
| 7. | "Монда җире дә, суы да шифалы,<br>Бик күп кара чимал табыла" | Ширманов Илнур | 5<br>5 |

«УТВЕРЖДАЮ»
Директор МБОУ «Зай-Каратайская ООШ»
муниципального образования
«Лениногорский муниципальный район» РТ
Ахметова Лейса Шагитовна
«        » ____________2017

АКТ
Обследования музея «Трудовой и боевой славы»

Адрес: 423273, РТ, Лениногорский район, село Зай-Каратай, ул.Уныш, дом№ 51
«        »______________2018 г.

1. Состав комиссии:
- Ахметова Л.Ш. – директор школы
-Валиева Г.Н.. – зам. директора по УВР
- Гимадиева Г.З.- председатель профсоюзной организации школы
- Насибуллина С.А. - председатель совета ветеранов села Зай-Каратай
-Галиуллина А.Х. – руководитель музея

2. Название музея, учреждения образования: Музей «Трудовой и боевой славы», Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Зай-Каратайская основная общеобразовательная школа» муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» РТ

3. Документация музея:
- приказ №28а от 5.11.1987 года о создании музея;
- паспорт музея;
- инвентарная книга;
- тематико-экспозиционный план;
- акты приема-выдачи;
- план работы кружка «Изучение родного края» при музее;
- книга отзывов;
- методические разработки

4. Экспозиции:

1.“Беркем дә, бернәрсә дә онытылмас”- наши земляки в ВОВ
2“.Үткәннәрне өйрәнми торып, хәзергене белеп булмый” – национальные экспонаты из быта татарского народа
3.“Җир йөзендә шундый авыл бар –
Зәй-Каратай диләр исемен... – история села Зай-Каратай

4.“Башы гыйлем чишмәсенең, мәктәп, бары синнән башлана” – история образования в селе Зай-Каратай
5.“Тарих бөтен фәннәрнең анасы, туган җирен яраткан һәр кеше үз тарихын белергә тиеш” – о Туйкинах
6.“Монда җире дә, суы да шифалы, бик күп кара чимал табыла” – земляки-нефтяники
7.Авылдашларыбыз-интернационалистлар – земляки- интернационалисты

5. Фонды музея: в музее насчитывается 400 музейных экспонатов

6. Руководитель музея: Галиуллина Асия Хайдаровна

7. Заключение комиссии: на основании вышеизложенного комиссия считает, что музею «Трудовой и боевой славы» МБОУ «Зай-Каратайская ООШ» муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» РТ присвоить звание «Школьный музей» на школьном уровне.

_____________/ Ахметова Л.Ш./

_____________/Валиева Г.Н../

________________ / Гимадиева Г.З./

_________________/Насибуллина С.А./

__________________/Галиуллина А.Х./